УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел./ факс: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**Казан шәһәре**

**7 февраль 2022 ел.** **№ 6**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе каршындагы иҗтимагый шура турында» 2015 елның 5 ноябрендәге 80 санлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе каршындагы иҗтимагый шура турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый шура турында бер төр нигезләмәгә үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең (алга таба – Идарә) 2015 елның 5 ноябрендәге 80 санлы боерыгы (2016 елның 9 мартындагы 14 санлы, 2018 елның 22 гыйнварындагы 9 санлы, 2019 елның 23 гыйнварындагы 5 санлы, 2019 елның 7 июнендәге 44 санлы, 2021 елның 3 декабрендәге 72 санлы боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе каршындагы иҗтимагый шура турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертегә:

6.6 пунктның икенче кызыл юлына «әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда» сүзләрен өстәргә;

6.7 пунктның икенче кызыл юлына «әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда» сүзләрен өстәргә;

6.8 пунктның икенче кызыл юлына «әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән биш көнлек чорда» сүзләрен өстәргә.

**Идарә җитәкчесе** **Г.Р.Нигъмәтуллина**